# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Минзәлә авыл җирлегенең Яңа Мәлкән торак пунктында гражданнарга үзара салым кертү турында**

**28 ноябрь 2024 ел** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында " 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Яңа Мәлкән авыл җирлегенең Яңа Мәлкән торак пунктында гражданнар җыены

Карар кабул ителде:

1. «Минзәлә муниципаль районының Яңа Мәлкән авыл җирлегенең Яңа Мәлкән торак пункты территориясендә 1 һәм 2 төркем инвалидларыннан, балачактан инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы, сугышчан хәрәкәтләр ветераннарыннан, Россия Армиясе сафларына хезмәткә чакырылган гражданнардан , махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2025 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау - Яңа Мәлкән торак пунктындагы артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу (эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү);
2) Яңа Мәлкән торак пунктындагы зират территориясен ремонтлау өчен төзелеш материаллары сатып алу (эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү).

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Яңа Мәлкән авыл җирлеге Советының мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Минзәлә муниципаль районы сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә. http://menzelinsk.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan кабул ителгәннән соң 10 көн дәвамында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: _________ Нәҗметдинов З.И.

Яңа Мәлкән авыл җирлеге башлыгы,

Совет рәисе_ ____________________ Нәҗметдинов З.И.